АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ ОБРАЗОВАНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ» АССОЦИАЦИЯСЕ

**РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА**

**ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 10.06.2021 № ПР-17-1

г. Казань

**«Цифрлы икътисад» милли программасының «Мәгълүмати инфраструктура» проектын гамәлгә ашыру буенча муниципаль берәмлекләрнең бурычлары һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү турында**

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең цифрлы үсеше, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумы (алга таба – Совет) **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең цифрлы үсеше, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә тәкъдим итәргә:

- социаль әһәмияткә ия объектларны Интернет челтәренә, шул исәптән устав документларына, тоташтыру өчен кирәкле мәгълүматларны Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына үз вакытында һәм оператив тапшыруны тәэмин итәргә;

- 2011 елның 1 августына кадәр мобиль элемтә муниципалитетлары территорияләренең каплануына анализ ясарга һәм тикшерү нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына җибәрергә;

- «Таттелеком» ачык акционерлык җәмгыяте һәм мобиль элемтә операторларына инфраструктура объектларын урнаштыру, шул исәптән җир кишәрлекләрен рәсмиләштерүдә, кирәкле эш алып баруда ярдәм итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Советның башкарма сәркатибе А.Г. Барышевка йөкләнә.

**Рәис** **Э.С. Гобәйдуллин**